**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КРЫНДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЫРЫНДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11.2020 с. Крынды № 24

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 9 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе эчке эшләр министрлыгының Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәү исәбенә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентын раслау турында» 2017 елның 31 декабрендәге 984 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 09 июлендәге 15 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә.

1.1. 1, 2 кушымталарда «йорт китабы» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырып халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

(https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе И. И. ЗАКИРОВ